ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2019 Казан шәһәре № 10-7/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019 елга кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 № 10-184/кс карарына кушымтаның 11 пунктына үзгәреш кертү хакында

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2019 елның 19 июлендәге СП/62069/19 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (көчәнешенә) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 2018 елның 11 декабрендәге 5-78/тэ номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 15 августындагы 5-4/тэ номерлы карары чыгарылуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019 елга кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 № 10-184/кс карарына кушымтаның 11 пунктына, аны киләсе редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «11 | «Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | |
| 11.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 13,82 | 14,21 | 1229,00 | 1271,91 |
| 11.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 11,52 | 11,84 | 1024,17 | 1059,92». |

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте

тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (көчәнешенә) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 2018 елның 11 декабрендәге 5-78/тэ номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 15 августындагы 5-4/тэ номерлы карары үз көченә кергән көннән башлап барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәлдә була, дип билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев